ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә.

2. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын рәсми бәяләмә алу өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.

3. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын, Россия Федерациясе Хөкүмәтеннән рәсми бәяләмә алганнан соң, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

5. Күрсәтелгән закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Гыйльметдинов Илдар Ирек улын билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 23 сентябре
№ 1617-VI ДС